**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав., 423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_________________ ________

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 19 августынданы №МПР-563 номерлы «Алкогольле продукциянең законсыз әйләнешен ачыклау һәм булдырмау буенча ведомствоара комиссия төзү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Югары сыйфатлы алкогольле продукция җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыру, аның ассортиментын киңәйтү, шулай ук ялган продукциянең эчке куллану базарыннан кысрыклап чыгару максатларында, шулай ук кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм бетерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 19 августында кабул ителгән ПР-563 номерлы карарының 1 пунктына үзгәреш кертергә һәм 1 нче кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә бәян итәргә.
2. «Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм бетерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 маендагы ПР-108 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru.үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны икътисад комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына
_______________ №___
1 нче кушымта

Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм бетерү буенча ведомствоара комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Бариев И.Ш. | - Башкарма комитет җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Сираева Л.Р. | Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| МирзашариповаО.М. | - Башкарма комитетның икътисад бүлеге башлыгы, комиссия секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Хәйретдинов И.И. | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгы; |
| Нурлыев Н.Н. | - район суд приставлары хезмәте җитәкчесе, өлкән суд приставы; |
| Хәев ХР. | - «Актаныш үзәк район хастаханәсе» баш табибы; |
| Кулиева И.Г. | - МРИ ФНСның баш дәүләт салым инспекторы; |
| Вафина Г.Л. | - ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Чаллы территориаль органы башлыгы; |
| Хафизова Л.М. | - Чаллы шәһәре «Роспотребнадзор» территориаль бүлек җитәкчесенең Актаныш районы буенча урынбасары; |
| Шәфикова Н.Р. | - «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Усманов Р.М. | - «Актаныш мәгълүмат-редакция үзәге» «ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы директоры; |
| Иманаев А.Р. | - Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Сәлимов Д.З. | - Башкарма комитетның юридик бүлеге башлыгы. |